| | | |
|---|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 29.08.2019 | | № 266 |

Алексеевск ш.т.б.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен раслау турында**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктына таянып

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**

Алексеевск муниципаль районының
29.08.2019 № 266 район Советы
карарына кушымта

**Алексеевск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль контроль төрләре исемлеген төзегәндә һәм алып барганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала (алга таба текст буенча - Исемлек).

1.2. Исемлекне төзү һәм алып бару түбәндәге принциплар нигезендә башкарыла:

- исемлеккә кертелергә тиешле муниципаль контроль төрләре турында белешмәләргә карата таләпләрнең бердәмлеге;
- исемлектәге белешмәләрнең дөрес булуы һәм вакытында актуальләштерелүе;
- исемлектә булган мәгълүматның ачык һәм һәркем файдалана алырлык булуы.

1.3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре турында белешмәләр исемлегенә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле белешмәләр кертү өчен нигез булып муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен билгели торган яисә аны гамәлгә ашыру тәртибен һәм (яисә) шартларын үзгәртә торган норматив хокукый актлар тора.

II. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару структурасы, тәртибе

2.1. Исемлеккә түбәндәге белешмәләр кертелә:

- Алексеевск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре исеме;
- муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнары исеме, аларның урнашкан урыны, телефоны;
- муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органы вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль норматив хокукый актының исеме һәм реквизитлары.

2.2. Исемлекне алып бару, андагы мәгълүматларның актуаль торышын тәэмин итү бурычы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла (алга таба - Вәкаләтле орган).
2.3. Исемлекне алып бару түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
- белешмәләрне исемлеккә кертү;
- исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү.
2.4. Исемлекне раслау, аңа үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан карар формасында хокукый акт кабул итү юлы белән гамәлгә ашырыла.
2.5. Исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен түбәндәгеләр нигез була:
- муниципаль контроль төренең исемен үзгәртү;
- муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исемен үзгәртү;
- тиешле җирле үзидарә органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында муниципаль норматив хокукый актның үз көчен югалтуын тану;
- башка җирле үзидарә органнарына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында муниципаль норматив хокукый акт чыгару;
- муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органы вәкаләтләрен туктату.
2.6. Мәгълүматларны исемлеккә кертү, аңа үзгәрешләр кертү, вәкаләтле орган тарафыннан, күрсәтелгән Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен Исемлектә булган нигезләр барлыкка килгәннән соң биш эш көне эчендә кертелә.
2.7. Исемлек Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

**Совет аппараты җитәкчесе** **А.С. Харитонов**